# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# КҮЗКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

## КАРАР

«08» ноябрь 2019 ел Күзкәй авылы № 18

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Югары Байлар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге уставы нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елның 22 ноябренә 10.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Югары Байлар авылы Совет, Яңа, 2-нче Яңа һәм Туганлык урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Югары Байлар авылы, Совет урамы, 29 йортында (Авыл клубы бинасында) билгеләргә.

2. 2019 елның 26 ноябренә 10.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Югары Байлар авылы Урман, 1-нче Яңа һәм Г. Шәрип урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Югары Байлар авылы, Совет урамы, 29 йортында (Авыл клубы бинасында) билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, Күзкәй авылында яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда яшәү урыны буенча Күзкәй авыл җирлеге Югары Байлар авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) юл төзекләндерү.

«ӘЙЕ» «ЮК».

5. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Күзкәй авыл җирлеге Башлыгы Э.Р. Гәрәев